| | |
|---|---|
| **СОВЕТ ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

**2019 елның 2 нче сентябре** **Федоровский авылы** **№ 13**

“Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында”гы Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы , “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 40 статьясына һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы Федераль законның 13.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 сентябре 19 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында»гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 статьяның 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдимнәр өстәргә: «Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат күрсәтелгән мәгълүматларны депутат булып сайланган көннән соң дүрт ай эчендә тапшыра, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырганнан соң яисә аның вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру туктатылганнан соң, шулай ук хисап чоры дәвамында мәгълүматлар тапшырган һәр ел өчен (хисап чоры), «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган. Хисап чоры дәвамында мондый килешүләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә Россия

Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) хәбәр итә.»;

11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә::

«2. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүмат биргән вазыйфаи затына, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтмәгән булса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү.;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан даими нигездә азат итү, вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү.;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати– телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://fedor-kaybici.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Федоровский авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Ф.Зайнуллин**